Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы

# КАРАРЫ

2021 елның 29 июле 62№

Әлки муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябрендәге «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү һәм шулай ук «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 91 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Әлки муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 91 номерлы карары белән расланган «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү һәм шулай ук «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы Нигезләмәнең (2020.05.06. 212№, 2015.18.12, 21№), 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«в) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, цифрлы финанс активлары, хисап чорында цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә

һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.»

2.Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин